РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

14. 08. 2023 Кукмара ш. № 452

«Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 18 августындагы 536 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 16 мартындагы 254 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә **карар бирәм:**

1. «Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 18 августындагы 536 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» (ТР Министрлар Кабинетының 2011 елның 18 октябрендәге 862 номерлы, 2012 елның 27 апрелендәге 331 номерлы, 2013 27 апрелендәге 287 номерлы, 2014 елның 06 октябрендәге 716 номерлы, 2016 елның 04 февралендәге 66 номерлы, 2018 елның 12 февралендәге 74 номерлы карарлары редакциясендә) сүзләрен төшереп калдырырга;

1 нче кушымтаның 1 нче пунктында «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен

булдыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Башкарма комитет житәкчесе **А.Х. Гарифуллин**